**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БАКРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 50-2-35, факс 50-2-35

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28 .11. 2023** **№ 12**

**2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә:

1. 2023 елның 15 декабрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Чуваш Чурапаны авылы, Канаш урамы, 25 йорт адресы буенча 2024 елда Тәтеш муниципаль районы Бакрчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаныо торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләнсен.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, волонтерлар) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

-Чуваш Чурапаны торак пунктында Маркс һәм Куйбышев урамнары киселешеннән Куйбышев урамындагы 1 нче йортка кадәр вак таш, ком сатып алу, нигез салу, ташу, салу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү сметасына ярашлы рәвештә юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча поселок эчендәге юлларны ремонтлау) ;

Чуваш Чурапаны торак пунктында зират территориясен саклау (төзү материаллары сатып алу, эш, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ремонтлау?

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https:tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Җитәкче** **И.М. Шәмсетдинов**